ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай
муниципальрайоны
муниципаль беремлеге
ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Старое Ильдеряково

**Совет Староильдеряковского сельского поселения**

Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603000718 БИК 049205805
КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП
Тел.: 4-47-30

КАРАР

№21 19.03.2021 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының
«Җир салымы турында» 2019 елның 28 ноябрендәге
115 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Салым кодексы 397 статьясының 1 өлеше нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай районы Прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 115 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә:

1.1 «Салым һәм аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьясы белән тулыландырырга. Салым салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatar.ru) һәм хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе: С.М. Маклаков